# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

23 ноябрь 2024 ел

№1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Мәлбагыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2024 елның 23 нояберендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

“Сез 2025 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә китүчеләрнең гаилә агъзаларыннан, РФ Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү өчен контракт төзегән гаилә әгъзаларыннан тыш, Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар,яктырткычлар,электр товарлары һәм махсуз җиһазлар сатып алу, алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

-Мәлбагыш торак пункты территориясен төзекләндерү (үләннәрне чаптыру,территорияне чистарту һәм чүп-чар җыю хезмәтләре күрсәтү; тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту ( яңа материал өстәп юлларны профильләү, Комсомол урамындагы юлларга асфальт салу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 334 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 175.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 175, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

Сез 2025 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә китүчеләрнең гаилә агъзаларыннан, РФ Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү өчен контракт төзегән гаилә әгъзаларыннан тыш, Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар,яктырткычлар,электр товарлары һәм махсуз җиһазлар сатып алу, алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Мәлбагыш торак пункты территориясен төзекләндерү (үләннәрне чаптыру,территорияне чистарту һәм чүп-чар җыю хезмәтләре күрсәтү; тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту ( яңа материал өстәп юлларны профильләү, Комсомол урамындагы юлларга асфальт салу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин